**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№2** **27.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге составына керүче,
Благодатное поселогында 2021 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Благодатное поселогында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Микулино авыл җирлеге Благодатное торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:
- Кыш көне юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- Үлән чабу һәм зираттан чүп чыгару;
- Щебенка сатып алу һәм Березовая урамы буенча юлны төзекләндерү;
- Благодатный поселогындагы христиан зиратына чүп-чар өчен мәйданчык һәм контейнерлар сатып алу һәм урнаштыру.
- Бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү («Сабантуй», «Авыл көне», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел»).

3. Өлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы И.А.Такиулин

МИКУЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002511
КПП 164301001